ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 23 декабре**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 3697**

Кадастр номерлары 16:49:011907:260, 16:49:011907:263 булган җир участокларын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

Д. Е. Бондинның, Д. А. Мусинаның кадастр номерлары 16:49:011907:260, 16:49:011907:263 булган җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турындагы мөрәҗәгатен карап чыгып, РФнең 29.12.2004 елгы 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексына, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗәне исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты
**КАРАР БИРӘ:**

1. Д. Е. Бондинга, Д. А. Мусинага кадастр номерлары 16:49:011907:260, 16:49:011907:263 булган җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә куллануга рөхсәт бирергә, рөхсәт ителгән куллануның бирелә торган төре - гомуми мәйданы 150 кв. м. дан артмаган «беренче кирәкле товарлар кибетләре».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Х. Сәхибуллин**